Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының кырык өченче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

19 ноябрь, 2024 ел № 116

Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге торак пунктлары территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыеннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге составына торак пункт пунктлары (торак пункт территориясе өлешендә) керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 164 номерлы Богородский авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. 1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авылы җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авылы җирлеге Көек авылы территориясендә (1 нче Үзәк ур., 31 нче йорт) 2024 елның 1 декабрендә 11.00 сәгатьтә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Көек авылы территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең чикләрен билгеләргә: 1нче Үзәк урамында җөп санлы йортлар 48 дән 74 кә кадәр, так санлы 13А дан 75 кә кадәр йортлар.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, 1 нче Үзәк урамында (җөп санлы йортлар 48 дән 74 кә кадәр, так санлы 13А дан 75 кә кадәр йортлар) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (1 нче Үзәк ур. (җөп санлы йортлар 48 дән 74 кә кадәр, так санлы 13А дан 75 кә кадәр йортлар)
«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге
башлыгы урынбасары В.М. Барышев